**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**«07» июнь 2024ел** **№ 99**

**Җирле салымнар суммасы буенча**
**бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның**
**өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына ярашлы җирле салымнар суммасы буенча өметсез бурычны җайга салу максатыннан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип танылa:
1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.
2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:
1) әлеге карарның 2 статьясының 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;
в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;
2) әлеге карарның 1 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 статьясының 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2023 елның 05 маендагы 74 номерлы «Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» (бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү, пенялар һәм җирле салымнар буенча штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында) карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе А. Г. Җиһаншин